# БИР КУЛЫҢНЫ, ГҮЗӘЛЕМ

*Ринат Гобәйдуллин көе*
*Халык сүзләре*

Агым суга ташламыйлар
Ак каен каерысын;
Аккошлар да бергә — бергә
Без нигә аерым соң?

*Кушымта:*
Бир кулыңны, гүзәлем,
Синсез өзелә үзәгем.

Иртән торып тәрәз ачтым
Гөрли күгәрченнәрем;
Бик сагындым, бәгырькәем,
Килә күрәселәрем.

*Кушымта.*

Сандугач баласын тоттым
Урман аланнарыннан;
Синең хәлләреңне сорыйм
Былбыл balaларыннан.

*Кушымта.*

Биек таудан чәчәк жыйдым,
Жыймадым сарыларын;
Үзең тапсаң, миңа да бир
Сабырлык даруларын.

*Кушымта:*
Бир кулыңны, гүзәлем.,
Синсез өзелә үзәгем.